КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 декабрь г.Казань № 1063

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 ноябрь, 899 нчы карары белән расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 ноябрь, 899 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 октябрь, 759 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Аларны каплауга субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре:

чит оешмалар хезмәт күрсәтүләре (брендлар һәм дизайн-проектлар эшләү, җиһазлар әзерләү, арендалау һәм сатып алу (шул исәптән күргәзмә стендлар), җиһазларны монтажлау, демонтажлау һәм утильләштерү (шул исәптән күргәзмә

стендлар), транспортлау, туплау, проект-менеджмент, инженер-проектлау эшләре, аккредитация, җиһазлар сатып алу һәм арендалау, экспозицияне сәнгатьчә бизәү һ.б.);

конгресс-күргәзмә чаралар үткәрү өчен мәйдан арендалау;

конгресс-күргәзмә чараларда катнашучыларның туклануын оештыру;

конгресс-күргәзмә чараларда катнашуга кертемнәр;

сувенир һәм тарату продукциясе, брендлы костюмнар тектерү;

конгресс-күргәзмә чаралар үткәрүне оештыру һәм аларда катнашу өчен өстәмә персоналны наемга алу;

персоналның очуы һәм яшәве, командировка акчалары, транспорт хезмәте күрсәтү;

видеоконтент эшләү;

чараны оештыруга субсидия алучының өстәмә чыгымнары (почта хезмәтләре күрсәтү, элемтә хезмәтләре күрсәтү, персонал хезмәте өчен түләү фонды, коммуналь хезмәт күрсәтүләр, оештыру техникасын карап тору, чыгым материаллары һәм канцтоварлар сатып алу).»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия түбәндәге шартларга җавап бирә торган юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) бирелә:

Татарстан Республикасының инвестицияләр җәлеп итү өчен кызыклы булуы турында мәгълүмат тарату максатында конгресс-күргәзмә эшчәнлеген оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыра;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгәннәр һәм үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыралар;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (оффшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты түгел;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаганнар.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия алу өчен юридик затлар Агентлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Агентлык раслаган форма буенча, чыгымнар сметасын һәм күргәзмә экспозициянең яки чараның (конгрессның, саммитның, форумның) эшлекле программасын беркетеп, гариза;

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлары булмауны раслый торган документлар;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы булмауны раслый торган документлар;

юридик затлар үзгәртеп оештыру, бетерү яки банкротлык процессында булмауны раслый торган документлар;

оешма әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормауны раслый торган документлар;

җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре.»;

6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язма кәгазе яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гариза бирүче әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы дүртенче абзацта, 6 пунктта каралган документларны тапшырмаганда, Вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

юридик затның әлеге Тәртипнең 2 һәм 4 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве

юридик зат тапшырган гаризадагы һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү Агентлык һәм субсидия бирү турында уңай карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү турында килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган үрнәк форма буенча билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң биш көн эчендә төзелә.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, Агентлык, Татарстан Республикасы дәүләт финанс контроле органы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруына субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма)

капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш), Агентлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча билгеле булган субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар субсидия алучы тарафыннан бозылган очракларда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару, субсидиянең хисап финанс елында файдаланмаган өлешен агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтару тәртибе һәм вакытлары билгеләнә.»;

16 пунктта «(шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары күчермәләре)» сүзләрен «, аерым алганда; башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, товар-транспорт йөкнамәләре, счетлар, счет-фактуралар, казна чеклары, чыгым ордерлары, түләү квитанцияләре, прокатка алу ведомостьләре, юл йөрү документлары.» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чара оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = E \times 100\%,$$

монда:

S – субсидия күләме, сум;

E – чара оештыру һәм үткәрү өчен гамәлдә тотылган чыгымнар, сум.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин